ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.01.2026 Олы Кайбыч ав. № 6

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районында гражданнар оборонасы штабын төзү турында» 2023 елның 04 сентябрендәге 343/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Граждан оборонасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 23 июлендәге 240-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районында гражданнар оборонасы штабын төзү турында» 2023 елның 04 сентябрендәге 343/1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтада:

- 1 бүлекнең 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнар оборонасы өлкәсендә таләпләр - - гражданнар оборонасы идарәсенең техник системаларын, сыену урыннарын һәм гражданнар оборонасының башка объектларын булдыруның, эксплуатацияләүнең, халыкка хәбәр итү системаларын куллануга, башка махсус техниканы һәм граждан оборонасы мөлкәтен файдалануга һәм карап тотуга даими әзерлек хәлендә махсус шартлар (кагыйдәләр, тәртип), халыкны индивидуаль яклау чаралары белән тәэмин итү, халыкны эвакуацияләүне оештыру, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән матди һәм мәдәни кыйммәтләрне яклауга әзерлек.»;

- 2 бүлекнең 23 абзацында «хәрби низагларда яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында халык өчен» сүзләрен төшереп калдырырга;

- 2 бүлекнең 24 абзацында «хәрби конфликтларда яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләрен «куркыныч килеп чыгу нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

- 2 бүлекнең 74 абзацында «хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килә торган» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
беренче урынбасар О.Д.Макарова